НАРОДНЫЙ ТЕАТР

# ВСТРЕЧАЯ СЛАВНЫЙ ЮБИЛЕЙ



**Наступивший год — юбилейный для драматического коллектива Абдрахмановского Дома народного творчества: он отметит 85 лет со дня основания и 20 — присвоения почетного звания «Народный».**

Подумать только: свой первый спектакль драмколлектив поставил на сельской сцене 7 ноября 1925 года! С той поры его состав многократно менялся, но в постановках, всегда наряду с представителями сельской интеллигенции (учителями, культработниками и сотрудниками сельсовета), играли и рядовые колхозники — доярки, скотники...

Последние 34 года и поныне, этим уникальным коллективом руководит Гамбария апа Сайфутдинова, внесшая огромный личный вклад в сохранение и развитие татарской культуры в Абдулинском районе. И сейчас, несмотря на свой 67 возраст, она полна бодрости, энергии и огромного желания продолжать радовать своего зрителя.

Ежегодно коллектив ставит два больших спектакля, обычно выбирая одну из драм или комедий любимых авторов — Туфана Миннулина, Фоата Садриева, Нажиба Асанбаева, и множество небольших сценок и скетчей. Премьеры обычно приурочиваются к праздникам: ко Дню пожилых людей, к Новому году или 8 Марта.

Абдрахмановский драмколлектив — единственный, удостоенный звания «народный» в районе и один из старейших в области. Является лауреатом и дипломантом многочисленных смотров и фестивалей, в том числе и областного уровня.

Все эти году самыми благодарными их зрителями были и остаются односельчане — часто по их многочисленным просьбам спектакли приходится повторять снова и снова...

**На снимке автора:** идет спектакль «Чаткылар» по пьесе Тажи Гыйззата.

**Зиля ЗАРИПОВА. Абдулинский район.**

ТУГАН ЯК

# Татар бит без, чын татарбыз...

**Җырлап торам,**
**торган җирем тар булса да,**
**Курыкмыйм, сөйгән**
**халкым татар булса да.**

**Габдулла ТУКАЙ.**

**«Туган җир! —**
**дип, сагынганнар**
**Туган җирен ташлап китә…**
**«Милләтем» —**
**дигәндә, кайчак,**
**Туган теленә хыянәт итә!»**
— диеп, яза бер шигырендә Ф.Мөслимова.

Татар халкы... Ул олуг, үз дәрәҗәсен белә торган, бай тарихлы, мул мәдәниятле, шанлы дәүләтләр тоткан халык.

Атаклы тарихчы Л.Н.Гумилев татар исеме турында: «Белегез, бу- горур исем!»- дип, юкка әйтмәгән. Шуңа күрә безгә юкбар өчен бәхәсләшеп йөрергә кирәкми. Чын татар кешесе үз халкының тарихы белән танышканнан соң, газиз милләтенең бөтенлеген саклау хакына дөрес юлны сайларга тиеш. Бөек шагыйребез Г.Тукайның түбәндәге мәңге онытылмас сүзләре искә килеп төшә:

**«И туган тел, и матур тел,**
**Әткәм, әнкәмнең теле.**
**Дөньяда күп нәрсә белдем**
**Син туган тел аркылы».**

Әйе, туган телдән якын тел, мөгаен, юктыр. Һәркем үз телен, тарихын, гореф-гадәтләрен белеп яшәргә тиеш. Кызганычка каршы, кайберәүләр үз телләрен белергә тырышмыйлар, аның белән хәтта кызыксынмыйлар да.

Менә без, Матвеевка районында торган татарлар, үзебезнең зонада чыгып килгән «Туган як» газетасын түземсезлек белән көтеп алабыз һәм шатланып укыйбыз. Бу очракта газетаның чыгуына ярдәм иткән өлкә Закончыгару депутаты И.Я.Дәүләтовка, газетаның баш мөхәррире Ф.Нугумановка зур рәхмәтләребезне белдерәбез. Әлбәттә, газета чыгару эше җиңелдән түгел. Шуңа да карамастан, «Туган як» газетасы чыгып, үзенең мәкаләләре белән безне сөендереп тора. Зур рәхмәт сезгә!

«Туган як» газетасын укыган милләттәшләребез! Онытмыйк әле без үзебезнең сүзгә бай татар телебезне һәм изге ислам динебезне.

**Без татарбыз, кем булсак та,**
**Гомум гадәт — телебез.**
**Милләт хисләрен якларга**
**Халыкларга телибез.**

**А.НИЗАМОВ, Матвеевка районы.**

РӘХМӘТ СҮЗЛӘРЕ

# Ягымлы йөзен күреп...

Матвеевка районы Иске Әшер авылы тарихка бай халык. Монда бик эш сөючән кешеләр яши. Менә Әлфирә Шамил кызы Муфтахова да үзенә бик кирәкле һөнәр сайлаган. Иске Әшер авылында туып, зифа буйлы булып үскән бу чибәр кыз ун классны тәмамлагач, Башкорт дәүләт медицина институтына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлагач, туган якларына кайтып эшкә урнаша. Ә хәзер район шифаханәсендә теш табибәсе булып эшли. Аның авырулар белән мөгамәләсе шулкадәр ихлас, йөзе ягымлы, хәтта шифаханәгә баргач Әлфирәне күреп, тешләреңнең үтереп сызлавын да онытасың. Мамыктай йомшак куллары белән «Чак кына түзегез инде», — дигән сүзләренә җан эри.

«Без аны кечкенәдән беләбез. Мәктәптә бик яхшы укыды, җәмгыять эшләрен алып баруда да катнашты. Шуңа күрә зур уку йортына кереп, кулына яхшы диплом алып чыкты» — ди, ветеран- укытучы Мая Кабировна Биктимирова.

Аның ике бертуган апалары да бик тәртипле, мәрхәмәтле булып үстеләр. Хәзер Рәфинә Екатеринбургта врч-инфекөионист, ә Рәшидә Ставрополь краенда чит телләр укытучысы. Әлфирәнең әтисе Шамил абый белән әнисе Нәсирә апа 30 ел буена икесе киносетьта эшләделәр. Авыл халкына кино күрсәтеп куандырдылар.

Авыл һәм район халкы исеменнән «Туган як» газетасы аркылы Әлфирәгә рәхмәт белдерәсебез килә. Киләчәктә аңа сәламәтлек, озын гомер, ак бәхетләр телибез.

**А.НИЗАМОВ, Матвеевка районы.**


# «Туган як» — газета твоего родного края!

Продолжается подписка с доставкой со следующего месяца на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край». **Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.** Концепция редакции — издание народной газеты, отвечающей пожеланиям жителей малых городов и сел.

# Дүрт сәбәп “Туган як”ка язылырга!

**1. Үзегез һәм якташларыгыз, бөтен татар дөньясы, курше районнар тормышы турында хәбәрләр укыйсыз.**
**2. Халкыбызның гөреф-гадәтләрен дин кануннарын өйрәнә аласыз, намаз вакыты күрсәтелә.**
**3. Үзегез язган теләкләрне, кинәшләрне, шигырләрегезне, хикәяләрегезне бастыра аласыз.**
**4. Татар халык ризыкларын әзерләргә өйрәнәсез.**

**ПОДПИСНОЙ ИНДЕКС — 53167.**

Оформить подписку можно в любом почтовом отделении или у почтальонов.
**Лучшие почтальоны будут поощрены материально.**
На газету можно подписаться с доставкой с марта месяца.

**СПРАВКИ ПО ТЕЛЕФОНУ РЕДАКЦИИ: 8(35351) 222-81.**